# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыркул авыл җирлеге составына керүче Кыркул авылы

13 ноябрь 2020 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Кыркул авыл җирлеге составына керүче Кыркул торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2021 елда Кыркул авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:
   - парк зонасын төзекләндерү;
   - җирлекэчендәге юлларны ремонтлау, төзекләндерүһәмкараптоту;
   - спорт мәйданчыгын коймалау;
   - каты көнкүрешкалдыкларыҗыюөчен контейнер әйданчыкларыурнаштыру;
   - су челтәрләрен реконструкцияләү;
   - дини объектларны төзекләндерү;
   - күмелгән урыннарны төзекләндерү.
3. Әлеге карарны Кыркул авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыркул авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кыркул авыл җирлеге башлыгы Е.А.Косова